Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең
Чаллы Башы авылы гражданнарының 2024 елда үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫНЫҢ КАРАРЫ

2023 елның 27 октябре №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Чаллы Башы авылы гражданнар җыены нигезендә

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлегенең Чаллы Башы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән, контракт буенча хезмәт итүче гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 1 төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче 75 яшьтән өлкәнрәкләрдән кала, һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту;

- халыкның күпләп ял итү урыннарын (парклар, скверлар, яр буйлары, пляжлар, спорт мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннарын) төзү, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү;

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау;

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

- традицион күмү урыннарын(зиратларны) төзекләндерү, ремонтлау, коймалар тоту.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.Шахмай авыл җирлеге Чаллы Башы авылы мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/,» Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет»

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге башлыгы Н.М.Илалова